# Рухи мирас җәүһәрләре

Шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Әбелмәних Каргалый
(Әбелмәних Әбелфәиз улы Габдессәләмов)ның 240 ел тууына

2022 ел - күренекле шагыйребез Әбелмәних Каргалыйның юбилей елы. Бу – татар әдәбиятын сөючеләр өчен шагыйрьнең шигъри җәүһәрләре белән генә танышып калмыйча, ул чорда кешеләрне дулкынландырган, борчыган, газаплаган хис-тойгыларны күз алдына китерер өчен бер күркәм сәбәп.

Азрак биографиясенә тукталсак, Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәләмов 1782 елда Оренбург янындагы Каргалы (Сәгыйть бистәсе) авылында туа. Бабасы Габдессәлам Казан өязе Мәңгәр авылыннан (1963 елның 1 февраленнән – Арча, 1990 елның 25 октябреннән Әтнә районы) Ташкичү һәм Ябәш авылларында имам-мөдәррис булып торган, шигырьләр дә язган. 1745 елда ул яңа гына төзелеп килгән Каргалыга барып урнаша, шунда ахун дәрәҗәсенә күтәрелә. Әбелмәнихнең шәкертлек еллары Каргалы мәдрәсәсенең шаулы чорына туры килә. Әбелмәних, әлеге уку йортын тәмамлагач, белемен арттыру өчен, Урта Азиягә китә. Бохарада Ниязколый Төркмәни мәдрәсәсендә белем ала һәм зур укымышлы булып танылa. Бохарада белеме, акыл иясе булуы белән әмир сарае дәирәсендә танылып, Төркиягә җибәрелә торган илчелек һәйятенә мулла һәм илчелек әгъзасы сыйфатында Истанбулга бара. Аннары Каһирә, Мәккә шәһәрләрендә дә була. Гәрәбстаннан, Истанбул аша, туган иленә – Каргалыга кайта. Берничә елдан соң ул яңадан хаҗга китә, шунда авырып, 1826 елда үлеп кала.

Бохарада укыган чагында Әбелмәних Каргалый шигырьләр иҗат итә башлый. Әбелмәних Каргалый әсәрләрен замандашлары бастырып чыгару чараларын күргәннәр, кулдан-кулга күчергәннәр. Әбелмәних Каргалыйның иҗат мирасы, аның әсәрләре төрле җыентыкларда урын алган.Әлбәттә, кульязмалар күчерелгәндә, хата да китәргә мөмкин. Шагыйрь әсәрләренең кулъязма текстларын, төрле күчермәләрен барлау эшләре алып барыла.

Кызганыч, суфи шагыйрь Ә. Каргалыйның иҗаты бүгенге көндә бик аз өйрәнелгән. Әбелмәних Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних» китабы билгеле. Ул Төркиядән Каргалыга кайткач язылган, бу китапка кертелгән сәяхатнәмәсендә ул үзенең чит илләрдә йөрүен һәм ватанына кайтуын тасвир итә. Бу китапның кульязма күчерелмәсе ТР Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Әбелмәних Каргалыйның гарәп графикасындагы китабы
Каргалый Ә. Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. – Казан: Казан университет табыгханәсе, 1889.-34 б.

Филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирасны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре Алсу Хәсәвнех бу әсәрне җентекләп өйрәнгән. « Әбелманих Каргалый хикәяләвендә Фудайл ибне Ийәд тарихы» дигән мәкаләсендә: «Каргалый иҗат иткән бу әсәр, үзенең структурасы һәм эчтәлеге белән төрле – төрле мотивларының, сюжет һәм тарихларның могҗизаи рәвештә үрелүеннән гыйбәрәт калейдоскопны хәтерләтә. Әсәрдә авторның үзенчәлекле интерпретация бар һәм нәкъ менә шул сыйфат шагыйрь иҗатының әһәмиятен күтәрә дә», - дип нәтиҗә ясый.




**Гайнуллин Мөхәммәт. Татар әдәбияты XIX йөз. 5 томда: Т. 3 – Казан : Татар китап нәшрияты, 1968. – Б. 27 - 30**

Бу китап беренче мәртәбә 1945 елда басылып чыккан. Әбелмәних үзенең тезмә итеп язган хикәяләрен тәрҗемә дип атый. Бу – дөрес. Ул аны гарәп телендә басылган чәчмә хикәяләрдән файдаланып язган. Шул ук вакытта аларның татар әдәбияты тарихында билгеле әһәмиятләре дә бар. Беренчедән, бу хикәяләрне ул тезмә формага күчерә, аларга шигъри төс бирә. Икенчедән, шул хикәяләрнең ахырында үз фикерләрен әйтә; урыны туры килгәндә яңа

күренешләргә багышлап, оригиналь юллар өсти.




**Шәмсетдин Зәки, Каргалый Әбелмәних. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр / төзүчесе Мәсгуть Гайнетдин. – Казан : «Имам» нәшрияте, 2002. – 152 б.**


«Әбелмәних Каргалый XIX йөзнең иң күренекле татарларыннан. Халыкара масштабта танылу – аңа тиң килгән башка шәхес тарихыбызда, әлегә билгеле түгел дисәк тә, ялгышмабыз... Аның шул унлап лирик әсәре генә әдәбиятка билгеле булса да, барыбер ул шигъриятебезнең иң күренекле, үлемсез шагыйрләреннән хисапланыр иде. Замандашларын инде ул мондый шигырьләре белән, чын мәгънәсендә сихерләгән».




**Садретдинов Ш., Гайнетдинов М. Әбелмәних Каргалый. – Казан, 1978. – Б. 35**

Элек ул Капус исемле иде,
Карбыз сату – даими шөгыле иде.
Карбызны кисеп ашаса һәр кеше,
орлыгын җыю иде моның эше.
Мисыр эчендә карбыз орлыгы бер заман,
Бик кыйбат булды, хакы чиксез яман.
Сатып гаять бай булды лэгыйнь,
Диде ахырда: «Галәм алласы – ул мин!»
Җан-тән белән җыеп көмеш һәм алтынны,
Ходай хакы өчен коры ипи телеме бирмичә,
Үзенә исә изгеләр исемен таккан.
Малын иманнан да газиз итеп саклап,
Изгеләр җөмләсеннән санар үзен, пычрак зат.

Ашаган чагында, капкасын бикләп куяр,
Фәкыйрьләрне кычкырып кире куар.
Мал мөлкәт сөю моннан да күбрәк булырмы?!
Кая инде кешеләргә юлбашчы булу?!




**Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре. – Казан университеты нәшр., 1982. – Б. 86-141**

Кызганычка каршы, Әбелмәних Каргалыйның үзе төзегән җыентыгы калмаган. Бүгенге көндә аның шигырьләре төрле китапларга кереп сакланып калган. Әлеге китапта әдипнең иҗат мирасы турында бай мәгълүмат бирелә. Каргалый тарафыннан иҗат ителгән «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних...» әсәренең текстологик үзенчәлекләренә, әсәрнең теленә күзәтү ясала, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләр тәрҗемә ителеп һәм шәрехләп бирелә.

Әбелмәних Каргалыйның иҗатына Риза Фәхретдин «Сәгыйд бистәсеннән чыккан бәгъзе мәшһүр кемсәнәләр» язмасында тормышын һәм иҗатын беренчеләрдән тикшерүче буларак шагыйрь турында кыскача мәгълүматлар да биреп, «Бу урында язылган шигырләр һичбер йирдә вә һичбер гасырда йөз кызартачак шәйләр дәгелдер», – диеп аның иҗатын югары бәяли.

Әсирлеккә төшкән дусты казый турында уйлану

Бәндә бәлагә төшкән икән, хурлык саналмас,
Тимер богауга төшкән, әлбәттә, арыслан булыр,
Ишәк белән дуңгызга игътибар булмас.
Чылбырга төшүдән арысланга гарьлек булмас.
Бер көе генә тормас дөньяның эше:
Бер югары, бер түбән булыр кеше.
Бетмәс дәүләт булыр камил гыйлем генә,
Мал-дәрәҗә бер килер дә бер китәр.

Туган ил

Туган илне сагыну һич китми икән,
Кайтам илемә, аңа җитми икән,
Ватан мәхәббәте иманнан ул,
Ир-хатынның үлгәнче саклаган тойгысы шул.

Әдәбият


1. Гайнетдинов М. Әбелмәних Каргалый // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Том 2. – Казан : Татар. китап нәшр., 1985. – Б . 125-138.
2. Гайнуллин М. Татар әдәбияты, XIX йөз. – Казан : Татар. китап нәшр., 1968. – Б. 27 - 48
3. Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре. – Казан университеты нәшр., 1982. – Б. 86-141.
4. Каргалый Ә. Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. – Казан : Казан университет табыгханәсе, 1889. – 34 б.
5. Садретдинов Ш., Гайнетдинов М. Әбелмәних Каргалый. – Казан, 1978. – Б. 35
6. Хасавнех А.А. Әбелманих Каргалый хикәяләвендә Фудайл ибне Ийәд тарихы // Фәнни мирас. – 2019. – Б. 48 – 53
7. Шәмсетдин Зәки, Каргалый Әбелмәних. Мөнәҗәтләр. Хикәятләр / төзүчесе Мәсгуть Гайнетдин. – Казан : «Имам» нәшрияте, 2002. – 152 б.
8. https://clck.ru/3323FZ